
Салават күпере журналына кушымта

№1

Сыбызгы



Башваткычлар Әкият Булмамышлар Кирле-мырлы арифметика



Йомран сыбызгысы бу!

Һич юк! Сыбызгылы йомран бу!

Ай-һай, бу йомран шәп сызгыра торгандыр, ә?

Ничек сызгырмасын! Йомран-Сыбызгы ич инде ул!

Сыбызгы мин, сызгырам,
Тәмле итеп сызгырам,
Ачы итеп сызгырам.
Җылак, кире кызларны
Һәм усал малайларны,
Тәртипсез балаларны
Ачуланам, кыздырам!
Мин – Сыбызгы-Йомран!..

Сызгырмыймын мәктәптә
Дәрестә дә сызгырмыйм.
Буран, давыл чыгар дип,
Өйдә дә мин сызгырмыйм,
Тузаннар да туздырмыйм.

Кирәк чакта сызгырам.
Ачы итеп сызгырам,
Тәмле итеп сызгырам
Мин — Сыбызгы-Йомран!



Бу Йомран-Сыбызгы була инде.

© "Сыбызгы", 1999 ел



Сы-быз-гы-ы-ы…

Сыбызгы итик, сыбызгы!
Ни өчен сыбызгы булды соң әле?
Нигә сыбызгы?!.
Ни сәбәпле без яңа журналчыкны «Сыбызгы» дип атарга булдык?..

Бер уйласаң, без барыбыз да сыбызгы борыннардыр әле!

Хәер, кем ничек тели, кемгә ничек ошый — әлеге исемнән шундый мәгънә эзләсен!

«Сыбызгы» — «Салават күпере» журналының карындаш туганы. Син дә аны нәкъ менә шулай итеп кабул ит!

Ә син үзен Йомран-Сыбызгы кебек сызгыра беләсеңме?



Кадерле укучым!

«Сыбызгы»ны өеңә алдыру өчен аңа аерым рәвештә махсус язылып торасы юк. Без аны «Салават күпере» журналының бер туганы дидек. Димәк, «Сыбызгы», «Салават күпере»нә язылган кешенең өенә ярты елга ике тапкыр сызгырттырып килеп керәчәк!











Рәссам Илдар Нәфиев

Беләсе иде

Әгәр колак салып тыңлап торсаң, дөньяда нинди генә тавыш юк!

Без ул тавышларга әллә ни игътибар да итмибез. Ияләнгәнбез, күнегеп беткәнбез инде. Әнә, ишетәсеңме: ут чыбыгына «кунып» җил сызгырып утыра. Нәрсә ди икән ул? Тавышына нык-лабрак колак салып карыйкчы. Бу матур һәм якты дөньяда бер батыр малай яки бер матур кыз яши икән ди бугай ул.

Ә нигә ут чыбыгына «кунып» сызгыра җил агай, нишләп шул рәвешле ачы иттереп сызгыра соң? Әнә, шәһәр урамында кешеләр ыгы-зыгы килә, чатыр-чотыр машиналар чабыша. Чү, әнә, милиционер абый сыбызгысын сызгыртты түгелме соң? Ә-ә-ә, монысы аңлашыла инде. Мөгаен, берәр бала светофорның кызыл күзенә дә игътибар итмичә урам аша чыгарга чамалыйдыр.

Әнә, бер малай җилләр белән узышып ат өстендә чаба. Тәгаен белеп әйтәбез: колак төбендә җил малае сызгырыпмы сызгыра инде аның! Тик нәрсә дип сызгыра икән соң ул, ни дип әйтергә тели икән? Их, беләсе иде шуны! Әнә, әнә, безнең Сыбызгы-Йомран аннан да көчлерәк сызгыра әле!

Карале, кара, куак очына без исемен белмәгән бер кош утырган да өздереп-өздереп сызгыра бит! Сыерчыкка да охшамаган бугай үзе? Нәрсә дип сызгырып утыра икән соң ул тиктомалдан? Шул рәвешле безне үртәвеме әллә? Беләсе иде бит, ә?

Уйласаң уй күп инде ул анысы. Әнә, телевизор экранында сугыш күрсәтәләр. Юк, юк, кино-фәлән түгел. Чын сугыш. Каядыр җылы якта, җиләк-җимешле якта кешеләр өстенә сызгырып пулялар оча, сызгырып бомбалар шартлый. Нигә сугыша бу өлкәннәр, ә? Ни җитмәгән инде! Хәер, мин моның сәбәбен беләм бугай. Әтидән дә сорап карарга кирәк әле. Ул белә микән?.. Югыйсә, әтәчләр сугышканда гел аера бит үзе.


Аптырагач, мин дә кесәмнән сөяк сыбызгымны тартып алдым һәм иреннәрем арасына кыстырдым. Сызгыртыйммы икән, юк микән, ә?.. Беләсегез киләме! Чынлаптамы? Күп беләсегез киләме? Әгәр дә мәгәр чынлап торып алай күп беләсең килә икән — «Сыбызгы»ны якын дус ит син, туганкаем! «Салават күпере» журналының туганы бит мин!..





Тапкырлар табарлар

тукайны дәресләп укы



Җәй көне. Эссе һавада мин комда
койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам,
башымны суга бәрәм.

Шул рәвешчә кичкә кадәр рәхәтләнеп уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез кибенмәм дип уйлагач,

Мүкәләп чыктым судан, тиз-тиз капладым өс-башым;
Шүрлим үзем әллә нидән, юк янымда юлдашым.

Бер вакыт кайтам дигәндә, төште күзем басмага;
Күрсәм: бер куркыныч әби утырган басмада.

Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,
Кара йөзле, кызыл кашлы, кызыл күзле кызларын.

Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабан туйларын
Язмыймын куркып еракларга китәр дип уйларым...



Тукта, мин юлдан адашканмын икән бит,
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит «Шүрәле».

Аз гына сабыр ит әле, и Кариэм! Хәзер язам;
Уйласам авлымны, гакълымнан да мин хәзер язам.

Шул турыда аз гына — биш-алты сүз сөйлим әле,
Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.

Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер җегет
Кышкы урманга утынга ялгызы бер ат җигеп.

Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,
Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.

Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

Укучым!
Тукай әсәрләре тәмам бутальп беткән монда.
Шулай бит?



Рәссам
Светлана Яркова

Өй эше I.

Укучым!

Бу сәхифәдә без сезгә өй эше бирәбез. Күрәсеңме, хәрефләр ничек буталышып беткән. Шуларны дөресләп яз да безгә җибәр. Иң тапкыр һәм өлгер баланы «Сыбызгы» бүләге көтә. Шуңа күрә тулы һәм дөрес итеп адресыгызны да язарга оныта күрмә, яме!

Аллы-артлы иҗекләр

Җөмлә башы:

* Леике ганал некөн камсум ырав лабу.
* Лебиш самал, камсум ңелҗи лабу.
* Неңлеике гырыкой бик ыноз.
* Ныларкыз канател аймал етег гелтү.
* Шакшап ныңлайма нырыбо гыбызсы бекке.
* Шакшап ныңкыз чечә ламапу.
* Мин негерәңбә феткон бекке тамяра.
* Генбү көн лыяшко.
* Чәки ыксу иде.
* Ларракяф дыгайсар.
* Ларкош лыҗы каяк текит.



* Без тәтәпмәк бызкыйу.
* Дәнтиз ларкулника тәҗи.
* Непләхәтрә гычаң бызаршу.
* Кыш ныбайба дымгынса.
* Ул ңами ләкбү ыпал ләки.



Сугыш чукмарлары

Кайсы як җиңәр?
Җавабын тап!



Уен муен түгел, муен чуен түгел.

Рәссам Юлия Щетинкина

Укучым!

Бу мәкаль-әйтемнәр дә сиңа өй эше итеп бирелә. Аларның мәгънәсенә үзең генә төшенә алмасаң, ярдәмгә өлкәннәрне дә чакыр. Үзеңә ярдәм иткән кешенең исем-фамилиясен дә язарга онытма.

Су ташканда балык тәкәббер була.

Дәрьядагы балык сатылмас.

Тавык белән ят, әтәч белән тор.

Ат дагалаганда бака ботын кыстырмас.

Ат алсаң — тешен кара, дус булсаң — эшен кара.

Ялкау төшкә кадәр йоклар, кичкә хәтле иснәр.

Ялкау энәне озын саплар.

Үзе салынкының аты табынкы.

Казынган казна табар, йоклаган йокы табар.

Уен төбе — уймак.

Күп уйнаган бер елар.

Уенның кайда уйнасаң, елавың шунда булыр.

Эшләмичә хак сорама.

Әй-һай синең йөрешең, бардыр синең бер эшең.

Өйләдән калсаң, өмәдән калма.

Үткән эшкә салават, калганына бәрәкәт.

Рәссам Фәрит Муллахмәт





Сызгыра торган БОРЫН

Борын-борын заманда Казан әле авыл гына, Дөбъяз авылы инде башкала булганда, самолетлар җәяү, атлар очып, балыклар мүкәләп, машиналар тәпиләп йөргән заманнарда ук булган ди, яшәгән ди Шакмай исемле бер малай. Бик тә, бик тә үзсүзле, ягъни кире булган икән ди бу малай. Кыш көне бүреген салып ыргыткан, җәй көне өстенә пәлтә, аягына киез итекләр киеп йөрмәкче булган ди. Тик әти-әнисе генә рөхсәт бирмәгән. Суыкта туңдырма ашаган, җәй көне чаңгы шуарга теләгән ди Шакмай.

Шулай кирле-сырлы йөри торгач, берзаман моның борынына томау төшкән бит! Мәктәптә укулар яңа гына башланган вакыт булган әле, көз көне инде; ичмаса, салкын кышта да түгел.

И сызгыра ди борын, мин сиңа әйтим! Шакмай тирән итеп суларга да курка икән. Карга баласы кебек авызын ачып кына сулап йөргән инде.

Өйдә булса да сызгырган теге борын, урамга чыкса да агач башында утыргач җилләрне уздырып сызгырган. Анысы — анысы... Мәктәп... Мәктәпкә дә барасы бар ич әле. Ярый тәнәфестә сызгырсын да, ди. Дәрестә сызгырып җибәрсә — ни хәл итмәк кирәк диген! Һәм борын аны-моны белмәгән, сызгырган. Дәрестә дә сызгырган!

Янәшәсендәге Миләүшә исемле кызның дәфтәренә күз салыйм дип, муенын гына боруы булган — борыны сызгырып җибәрмәсенме! Күршесеннән күчерә дә алмаган инде. Шуның өчен үзенә чыбыркы хәтле койрыклы икеле билгесе эләккән икән. Мәктәптән кайтканда





да сызгырган борын. Сыз-быз, быз-сыз ди һаман. Шулай мәктәптән кайтышлый борынның сызгырып җибәрүе булган — аның сызгырган тавышына сумка төбендә яткан «икеле»нең коты башына төшкән. Куркуыннан сумкадан ук сикереп чыккан да Шакмайдан алда өйгә таба элдергән ди! Шакмай аның артыннан йөгергән. И куышалар икән болар: «Икеле» чаба ди, аның артыннан Шакмай элдерә. «Икеле» чаба ди, Шакмай чаба ди. Шакмай аның койрыгына басам, менә-менә эләктерәм дигәндә генә, теге тагын алга ыргыла ди. Боларны күреп урамдагы бар җан иясе көлә икән! Барча халык эчен тота-тота шыркылдый икән! Вәт кәмит, менә кызык икән ди!

Узып-сызып йөрүче абыйлар-апалар, тыз-быз килгән машиналар, тавыклар, әтәчләр, песиләр, чыпчыклар да шау килеп көлә икән ди болардан.



«Икеле»нең койрыгы бик озын булган дидек бит инде. Шакмай аны тотам, койрыгына басам дигәндә генә — теге хәерсез борын сызгырып җибәрә дә — «икеле» тагын куркып чаба икән!

Икеле белән Шакмай әлсерәшеп-йөгерешеп өйгә кайтып керәләр ди берзаман. «Икеле» ишек ярыгыннан да сыйган ди. Өйгә килеп кергән дә, Шакмай әнисенең аягына уралган икән. Әни кеше исә абынып киткән, чак егылмый калган. Әтисе тотып калган ди.

Шуннанмы? Шуннан әти кеше каты итеп Шакмайның борынын кыскан ди. Һәм борын сызгыруыннан туктаган ди.

Рәссам
Светлана Ибраһимова





Кирле-мырлы арифметика

● Шакмай атлы малай әнисе өч сүз әйткәндә җавапка ике тапкыр күбрәк сүз әйтә, ә апасы ул авызын ачканчы 1 генә сүз әйтеп өлгерә. Шакмайның апасы нигә сүз әйткән?

● Шакмайның Акбай кушаматлы эте бер өрүдә янәшәсендә бергә җыелып торган 6 тавыкның котын очыра ала. Ике тапкыр өрсә, әлеге сан чаклы тавык та курыкмый Акбайдан. Икене өрүдә Акбай ничә тавыкны өркеткән?

● Шакмай бер атнага 4 «икеле» ала. Икенче атнада ул аның 2сен «тозлап» куя, калган икесен сумкасыннан куып чыгара. Ике атна эчендә Шакмай ничә «2»ле ала алыр иде?



Кирле-мырлы арифметика

● Шакмай бер көнгә 9 кешене ялганлый. Икенче көнне бу сан ике тапкырга артык була. Ә өченче көнне исә ул шуның яртысын күрше малай сумкасына салып куя. Шакмайның үзенә ничә ялганы кала?

● Шакмай атлы малай бер сәгатькә 5 кешегә вәгъдә итә. Сәгать саен шуларның икесен җилгә очыра барса, Шакмай 3 сәгатьтә ничә вәгъдәсен үти алыр иде?

● Шакмай әтисенең мыегында 99 төк бар, ә бабасыныкында 10га кимрәк. Бабайның мыегында ничә төк бар икәнен исәплә тап.

Рәссам
Фәрит Муллахмәт





Иң-иң-иң яшь, иң-иң-иң сәләтле рәссам **Алсу Мингалимова** иҗаты белән күпләрегез таныштыр инде. Аның кызыклы һәм мавыктыргыч рәсемнәре 1994 елда «Салават күпере» журналында тәүге тапкыр дөнья күрде.

Киләсе «СЫБЫЗГЫ» тулысынча Алсуның иҗатына багышланачак.





Баш мөхәррир **Зиннур ХӨСНИЯР**
Баш мөхәррир урынбасары Фирая БӘДРЕТДИН
Бүлек мөхәррире Ләбиб ЛЕРОН
Бизәлеш мөхәррире Диләрә НӘУРУЗОВА
Компьютер дизайны Мөнирә Аузиева
Исәп-хисап бүлеге Рәмзия САЛИХ
Тышлыкның 1нче битендә Диләрә НӘУРУЗОВА рәсеме

СЫБЫЗГЫ

1 – 1999
«Салават күпере» журналына кушымта

Редакция адресы: 420012 Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 14 нче йорт.
«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.
Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 17.9.99 ел. Басарга кул куелды 17.9.99 ел.
Тиражы 12593 данә. Заказ 3-527. Бәясе килешү буенча.